Ярты гасы



рдан артык Саранск шәһәре №4 балалар поликлиникасында хезмәт итvче ак халатлы шәфкать туташы Альфия Касим кызы Ахметдинова тәжрибәле белгеч кенә тvгел, ә хезмәттәшләре арасында абруйлы остаз һәм нәни пациентларынын яраткан дусты да. Акыллы, тырыш, мәрхәмәтле, тәжрибәле булганы очен, ул коллегалары, шәһәр халкы арасында хормәт казанган. Ә балалар аны «Икенче әни» дип тә йортә. Йозеннән елмаю китмәгән ягымлы шәфкать туташы һәр кечкенә пациентны яратып каршылый. Хезмәтендәге унышлары очен Мордовия медицина министрлыгыннан, Госсобрание, Правительство Республики Мордовия дипломнары, грамоталары белән бvләкләнгән. «Шулай да ин зур бvләк - савыккан балаларнын, аларнын әти-әниләренен елмаюлы карашларын кvрv, эшеннен нәтижәсеннән рәхәтлек алу», - ди Альфия Касим кызы. Язма героебыз тумышы белән Ләмберә районы Татар Тавласындагы хормәтле мәктәп директоры Касим Хайдәр улы белән Саранск механик заводынын мактаулы хезмәткәре Сания Юсыф кызы гаиләсендә доньяга килә. Альфия Касим кызынын тырыш булуы һәм булдыклылыгы балачактан ук кvренеп тора: Саранск шәһәре 22нче мәктәбен тәмамлагач, Саранск медицина училищесында (1972-75 еллар) “Медсестра детских учреждений” белгечлеген алып чыга.
Шуннан Саранск шәһәре № 1 поликлиникасында участковый табиб буларак хезмәт биографиясен башлый һәм шунда 20 ел хезмәт итә. Анын карамагында 800 шәхси (частный) сектор балалары була һәм авыру балалар янына яз башы, коз коннәрендә резинка итектән генә vтеп булган, шуна итекләре поликлиникада ук торган. Беренче тапкыр 2 кг авырлыкта туган балага инъекция ясарга бара.
- Балаларны бик яратам, - ди Альфия ханым Ахметдинова. - Шунадыр, эштәге авырлыклар да онытыла.
Анын хезмәт кенәгәсендә (Трудовая книга) бер генә язма бар, чонки переводом №4 поликлиникага эндокринолог янына шәфкать тутышы буларак кvчерелә. Бvгенге кондә

220 хезмәткәрле тату коллективта эшли.



Альфия Касим кызы Ахметдиновадан хезмәт vзенчәлекләре турында да сораштым һәм ул яраткан нәни пациентлары турында сойләде:
- Шикәр авыруы, шикәр диабеты, шикәр чире – эндокрин системага бәйле, инсулин гормонынын абсолют яки олешчә житешмәве аркасында гипергликемия (кан составында глюкозанын кvтәрелvе) башлана торган авырулар торкеме. Кызганычка каршы бvген балаларыбыз бу авырулар белән кvп авырый. Мәсәлән, безнен участокка караган Химмаш жирендә 60 бала шул чир белән азаплана, ә ун ел элек 21 бала гына авырады. Ожирение, щитовидка белән дә пациентларыбыз кvп авырый. Профилактик чараларны еш vткәрәбез, 6-10 һәм 15-17 яшьлек мәктәп балаларын тикшерәбез; анализлар нәтижәсе буенча я табибка юллыйбыз, я поликлиникага учетка алабыз. Ә бит балалар дорес тукланмый: фасфуд, майонез кебек зыянлы ризыкларны кvп ашый. Бу исә организмга тәэсир итми калмый, баланын иммунитеты аксый. Әти-әниләргә берничә кинәш: саф һавада кvбрәк булырга; дорес тукланырга; физик яктан ныгырга, әти-әниләргә балага карата назын, игътибарын кызганмаска, мәхәббәтен ешрак белдереп торырга; бала еш авырганда табиб белән кинәшләшеп, иммунитетны ныгыта торган махсус препаратлар, витаминнар бирv кирәк. Шулай ук vләннәр ярдәмендә сәламәтлекне ныгыту да файдалы. Әйтик, кура жиләге яфрагы иммунитетны ныгыта.



Балалар табибы булу жинелләрдән тvгел шул. Альфия ханым фикеренчә, бу һонәрдә беренче чиратта сабыр, тvзем булу сорала. Кvпмедер дәрәжәдә психолог булу да кирәк.
- Шәфкать уташы балалар белән генә тvгел, аларнын әти-әниләре, әби-бабайлары белән дә эшли. Барысын да бәйнә-бәйнә анлатырга туры килә. Балалар торле - кvкрәк сабыйлары, балалар бакчасына, мәктәпкә йори торганнары, vсмерлек чорына житкәннәре бар. Һәрберсе белән уртак тел табарга кирәк. Эшенне яратып башкаруынны балалар да сизә һәм Альфия Касимовна да шундый,- ди хезмәттәш докторы Сергей Вячеславович Бамбурин (рәсемдә).
Альфия Касим кызы белемле, һәрчак ярдәмгә килергә әзер булуы белән балалар кvнелен яулаган. 50 ел эшләv дәверендә бай тәжрибә туплаган шәфкать туташынын гаиләсе дә матур. Наиль Сәрвәртдин улы белән ике бала – Тимур белән Маргаритага тиешле тәрбия, белем биреп олы юлга озаталар. Бvген оныклары – Алия (9 кл.), Ринат (3 кл.), Артур (7 яшь) шатландырып тора аларны. Милли традицияләрдә тәрбияләнгән Альфия Касим кызы милли бәйрәмнәребезне хормәт итә, татарлар яратып пешергән пәрәмәчләребезне гаиләсендә генә тvгел, коллективында да бик тә яраталар.
Халыкара шәфкать туташлары коне vтсә дә, шул унайдан Альфия Касим кызын һәм бу шәфкатьле һонәргә гомерләрен багышлаган барлык белгечләрне дә бәйрәмнәре белән тәбрикләп, аларга соклануыбызны, ихтирамыбызны белдерик, жылы теләкләребезне юллыйк.

**Наилә НАСЫРОВА**